| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **Исполнительный комитет Сарлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района** | | **Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитеты** |
| ул. Центральная, д.68А, с. Сарлы, 423315<br>Тел. 365-34 | | Үзәк урам, 68А,<br>Сарлы авылы, 423315<br>Тел. 365-34 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» сентябрь 2018 ел № 15

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

"2019 елда Сарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) ял итүне оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары:

- ТР, Азнакай районы, Сарлы авылы, Үзәк урамы, 68А йорты;

- ТР, Азнакай районы, Бүләк авылы, Үзәк урамы, 26Б йорт

- ТР, Азнакай районы, Сөендек авылы, Зеленая ур., 34 й.

- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru,

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

Башлык М.Р.Шәрипов